**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

# КАРАР

«29» декабрь 2021 ел № 19/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номеры, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Советының 2018 елның 22 маендагы 6/1 номерлы карары (2018 елның 15 ноябрендәге 25/1 номерлы, 2020 елның 22 маендагы 3/2 номерлы карар үзгәрешләре белән) белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткрләрнең хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының ул электән биләгәнгә караганда югарырак төркеменә кергән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул биләгән вазыйфа кергән вазыйфалар

төркеме өчен беренче класс чинын биргәнчегә кадәр класс чины өчен аның оклад күләмен исәпләү 3 процентка тигез булган вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып башкарыла.

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының ул электән биләгәнгә караганда түбәнрәк төркеменә кергән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән һәм аңа электән биләгән вазыйфа буенча класс чины бирелгән очракта, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү 7 процентка тигез булган вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып башкарыла.».

1.2. Нигезләмәнең 1 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

Акчалата бүләкләүнең һәм
акчалата кызыксындыру түләвенең иң чик күләмнәре

| **Вазыйфа исеме** | **Акчалата бүләкләү (сумнарда)** | **Акчалата кызыксындыру түләве (сумнарда)** |
|---|---|---|
| Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы | 15759 | 8826 |

1.3. Нигезләмәнең 2 кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| **Вазыйфа исеме** | **Хезмәткә түләүнең 12 төркеме** |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 15753 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 15293 |
| Әйдәп баручы белгеч | 12763 |
| 1 категорияле белгеч | 11498 |

2. Әлеге карар 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Иске Дөреш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.М. Дусадбеков